**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗАРЕЧЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ЗАРЕЧНЫЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

423008, РТ, Нурлатский район п. Заречный,
ул. Черемшанская, д.5

Чирмешән ур., 5нче йорт, ТР,
Нурлат районы, Заречный
авылы, 423008

Телефон: 8 (84345) 38613, факс 38613 E-mail: Zarech.Nur@tatar.ru, сайт: http://nurlat.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Заречный пос. **КАРАР**

«21» ноябрь 2022 ел № 15

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлегенең Торнаяс авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елның 1 декабрендә 14 сәгать 00 минутка Торнаяс авылы, Урман урамы, 26нчы йорт адресы буенча урнашкан Торнаяс авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районының Торнаяс авылында Урман урамында 1-52 санлы йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2022 елның 1 декабрендә 16 сәгать 00 минутка Торнаяс авылы, Урман урамы буенча, 92нче йорт янында Нурлат муниципаль районының Торнаяс авылында Урман урамында 53-104 йортларда яшәүчеләрдән элек расланган карарларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча:
Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлегенең Торнаяс авылында 25.10.2022 ел № 1 торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар; Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Зареченский авыл җирлегенең Торнаяс авылында 25.10.2021 № 4 гражданнар җыены карарына үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Торнаяс поселогында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Турнояс авылында, Заречный авыл җирлегендә 25.10.2022 ел № 1 торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләрен һәм Нурлат муниципаль районының Зареченский авыл җирлегендә 25.10.2022 ел № 4 торак пунктында гражданнар Җыенының элек кабул ителгән карарын үз көчен югалткан дип танырга һәм җыенда яңа карар кабул итәргә:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге Торнаяс поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары толларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 3000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм әлеге кертемнәрне түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Турнояс авылы чикләрендә авыл эчендәге җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;

- уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру

-МТЗ-82.1 тракторы сатып алу.

« РИЗА»  «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Торнаяс авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Заречный авыл җирлеге башлыгы  Т.В Забойдулина